| | | |
|---|---|---|
| МИНИСТЕРСТВО<br>ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И<br>СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ<br>РЕСПУБЛИКИ<br>ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ<br>БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ<br>СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ<br>МИНИСТРЛЫГЫ |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

10.11.2022 Казан ш № 998

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 10.11.2022 ел, №998 боерыгы белән расланды

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган үзгәрешләр

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Аз тәэмин ителгән гаиләдән балага пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 643 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 31.07.2015 №533, 06.06.2016 №316, 28.11.2016 №668, 29.03.2017 №194, 08.06.2017 №349, 22.12.2017 №895, 07.05.2018 №351, 18.09.2018 №885, 02.04.2019 №221, 03.09.2019 №666, 14.11.2019 №1012, 06.02.2020 №71, 01.06.2020 №380, 31.12.2020 №1011, 04.05.2021 №289, 31.08.2021 №624, 01.10.2021 №714, 19.04.2022 №293 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Аз тәэмин ителгән гаиләдән балага пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

2 бүлектә:

түбәндәге редакциядә 2.3.3 пунктын өстәргә:

«2.3.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып реестр язуы тормый.»;

түбәндәге редакциядә 2.3.4 пунктын өстәргә:

«2.3.4. Балага пособие билгеләү турында карар реквизитлары:

карар номеры һәм датасы;

карар кабул итүгә вәкаләтле органның исеме;

гаризаның номеры һәм датасы;

мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);

карар кабул итүгә вәкаләтле затның (алга таба – вәкаләтле зат) вазыйфасы;

Вәкаләтле затның фамилиясе, исеме, ата исеме (соңгысы – булган очракта);

электрон имза турында белешмәләр.

Балага пособие билгеләүдән баш тарту турында карар реквизитлары:

балага пособие бирүдән баш тарту турында карар номеры һәм датасы;

карар кабул итүгә вәкаләтле органның исеме;

Мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);

мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документлар;

балага пособие бирүдән баш тарту турында карар кабул итү нигезләре;

вәкаләтле затның вазыйфасы;

Вәкаләтле затның фамилиясе, исеме, ата исеме (соңгысы – булган очракта);

электрон имза турында белешмәләр.»;

2.4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4.1. Гариза һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан шәхсән тапшырылган очракта, дәүләт хезмәте Үзәк бүлекчәсе тарафыннан гариза һәм әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән документлар теркәлгән көннән алып 10 календарь көн эчендә күрсәтелә.

Гариза һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар почта аша юллап җибәрелгән очракта, дәүләт хезмәте Үзәк бүлекчәсе тарафыннан гариза һәм әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән документлар теркәлгән көннән алып 10 календарь көн эчендә күрсәтелә.

Гариза һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы шәхси кабинет аша бирелгән очракта, дәүләт хезмәте Үзәк бүлекчәсе тарафыннан гаризага эшләр номенклатурасы нигезендә номер һәм Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы шәхси кабинетта чагылдырыла торган «Документлар тикшерү» статусы бирелгән көннән башлап 10 эш көне эчендә күрсәтелә.»;

2.4.4 пунктта «салымнар һәм җыемнар» сүзләрен «салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәрен түләү» сүзләренә алмаштырырга (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була);

2.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

2.6.2. Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары аша түбәндәге мәгълүматлар алына:

яшәү урыны һәм тору урыны буенча теркәлү исәбе турында (Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгыннан);

опека (попечительлек) билгеләү һәм опекунның (попечительнең) бала асраугa акча алуы турында (җирле үзидарә органнарыннан);

балага пособие билгеләү мәсьәләсен хәл иткәндә исәпкә алына торган физик затларның керемнәре турында (Федераль салым хезмәтеннән);

баланың тууын дәүләт теркәвенә алу турында (Федераль салым хезмәтеннән);

өйләнешүне (аерылышуны) дәүләт теркәве турында (Федераль салым хезмәтеннән);

үлемне дәүләт теркәвенә алу турында (Федераль салым хезмәтеннән);

баланы тәрбиягә алучы гаиләгә тапшыру һәм тәрбиягә алучы ата-аналарга тиешле түләү суммалары турында (җирле үзидарә органнарыннан);

ата-аналык хокукыннан мәхрүм ителү турында яисә ата-аналык хокукында чикләнү турында (җирле үзидарә органнарыннан);

күчемсез мөлкәт булуы турында (Росреестрдан);

транспорт чаралары, үзйөрешле транспорт чаралары һәм техниканың башка төрләре булуы турында ( Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгыннан);

торак урынын билгеләнгән тәртиптә яшәү өчен яраксыз дип тану турында (җирле үзидарә органнарыннан);

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү буенча бурычлар булуы (булмавы) турында белешмәләр (Федераль салым хезмәтеннән);

индивидуаль шәхси счетның иминият номеры турында (Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан) (әлеге абзац таләпләре 2023 елның 1

гыйнварыннан гамәл була);

баланы (балаларны) гомуми белем бирү оешмасында укыту турында (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгыннан);

әҗәте булган затның иректән мәхрүм итү, арест астында тору, мәҗбүри дәвалануда булу рәвешендә җәза үтүгә бәйле рәвештә алимент түләттерелә алмый торган затның кереме булмавы турында (Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан) (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була);

алимент түләүдән качу сәбәпле ата-аналарны эзләтү турында (Федераль суд приставлары хезмәтеннән);

ата-аналарны җинаять кылган өчен җинаять җаваплылыгына тарту турында (Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтеннән);

вәкил вәкаләтләрен раслаучы документ турында (Федераль нотариаль палатадан);

паспортның гамәлдә булуын тикшерү турында (Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгыннан);

фамилия-исем төркемнәренең, туу датасының, җенеснең һәм СНИЛС туры килүе турында (Федераль салым хезмәтеннән);

18 яшькә кадәрге инвалид баланы яисә балачактан I төркем инвалидны яисә хезмәткә сәләтсез затларны караган затлар турында (Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан) (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була);

мөрәҗәгать итүченең яки аның гаилә әгъзаларының иректән мәхрүм итү урыныннан чыгарылуы турында (Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтеннән);

мөрәҗәгать итүченең һәм гаилә әгъзаларының ИНН турында (Федераль салым хезмәтеннән);

«һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын куллану кысаларында алынган керемнәр күләме турында (Федераль салым хезмәтеннән);

Россия Федерациясе субъекты тарафыннан билгеләнгән чорда элегрәк алынган түләү турында (Социаль тәэминатның бердәм дәүләт мәгълүмат системасыннан);

ата-ананың икенчесенең түләүне алмавы турында (Социаль тәэминатның бердәм дәүләт мәгълүмат системасыннан);

фамилиясен, исемен, әтисенең исемен алыштыру турында (Федераль салым хезмәтеннән).

Мөрәҗәгать итүче Бердәм портал, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша мөрәҗәгать иткән очракта, мөрәҗәгать итүче паспортының чын булуын раслау турындагы белешмәләр ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча өстәмә рәвештә алына.

Мөрәҗәгать итүче югарыда аталган белешмәләрне раслый торган документларны үз инициативасы белән дә тапшырырга хокуклы.

Әлеге документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмалардан алынырга мөмкин, шул исәптән, мондый мөмкинлек булганда, электрон формада да, һәм әлеге пунктта каралган документларны тапшыру өчен әлеге Регламентта каралган тәртиптә тапшырылырга мөмкин.

Мөрәҗәгать итүченең югарыда күрсәтелгән документларны тапшырмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

2.8.1 пунктта «салымнар һәм җыемнар» сүзләрен «салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәрен түләү» сүзләренә алмаштырырга (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була);

2.8.2 пунктның алтынчы абзацында «салымнар һәм җыемнар» сүзләрен «салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәрен түләү» сүзләренә алмаштырырга (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була);

2.12.4 пунктның «в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) Үзәк бүлекчәсе хезмәткәрләре тарафыннан инвалидларга башка затлар белән бертигез рәвештә дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен комачау иткән каршылыкларны бетерүдә кирәкле башка ярдәмне күрсәтү;»;

2.14.5 пунктын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Алдан язылу булмау мөрәҗәгать итүчене чират тәртибендә кабул итүгә комачауламый.»;

3 бүлектә:

3.3.1 пунктның ундүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Формалаштырылган гарызига формат-мантыйкый тикшерү Бердәм портал тарафыннан автомат рәвештә, гарызнамәдә электрон форманың һәр кырын мөрәҗәгать итүче тарафыннан тутыру барышында орган (оешма) билгели торган таләпләр нигезендә гамәлгә ашырыла. Бердәм порталда мөрәҗәгатьнең электрон формасындагы кырлар тәгәлсезлекләр белән тутырылган булуы ачыкланган очракта, турыдан-туры мөрәҗәгатьнең электрон формасында мәгълүмат җиткерү юлы белән, мөрәҗәгать итүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында хәбәр ителә.»;

3.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4. Ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга (оешмаларга) җибәрү

3.4.1. Үзәк бүлекчәсендә теркәлгән гариза гарызнамә җибәрү өчен нигез булып тора.

3.4.2. Үзәк бүлекчәсе белгече электрон рәвештә түбәндәге белешмәләрне ала:

банктан яисә Үзәк белән үзара хезмәттәшлек турында килешү төзегән башка кредит оешмасыннан блокка куелган максатчан шәхси счет реквизитлары турында (мөрәҗәгать итүче өч яшькә кадәрге баланың ата-анасы (законлы вәкиле) булган очракта)(«Ак Барс Банк» ГАҖ);

баланың тууын дәүләт теркәвенә алу турында (Федераль салым хезмәтеннән);

өйләнешүне (аерылышуны) дәүләт теркәве турында (Федераль салым хезмәтеннән);

үлемне дәүләт теркәвенә алу турында (Федераль салым хезмәтеннән);

пенсия, пособиеләр һәм башка шундый ук түләүләр, шул исәптән мәҗбүри социаль иминиятләштерү буенча һәм Россия Федерациясе законнары һәм (яисә) Россия Федерациясе субъекты законнары нигезендә алынган компенсация характерындагы түләүләрнең суммалары турында.

3.4.3. Балага пособие билгеләү турында карар кабул итү өчен кирәкле белешмәләр Үзәк бүлекчәсендә булмаган очракта, Үзәк бүлекчәсе белгече ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасы ярдәмендә түбәндәге белешмәләрне бирү турында электрон рәвештә рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрә:

яшәү урыны һәм тору урыны буенча теркәлү исәбе турында (Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгында);

опека (попечительлек) билгеләү һәм опекунның (попечительнең) баланы асрауга акча алуы турында (җирле үзидарә органнарына);

балага пособие билгеләү мәсьәләсен хәл иткәндә исәпкә алына торган физик затларның керемнәре турында (Федераль салым хезмәтенә);

баланың тууын дәүләт теркәвенә алу турында (Федераль салым хезмәтенә);

өйләнешүне (аерылышуны) дәүләт теркәвенә алу турында (Федераль салым хезмәтенә);

үлемне дәүләт теркәвенә алу турында (Федераль салым хезмәтенә);

баланы тәрбиягә алучы гаиләгә тапшыру һәм тәрбиягә алучы ата-аналарга тиешле түләү суммалары турында (җирле үзидарә органнарына);

ата-ана хокукыннан мәхрүм ителү турында яисә ата-ана хокукында чикләнү турында (җирле үзидарә органнарына);

күчемсез мөлкәт булуы турында (Росреестрда);

транспорт чаралары, үзйөрешле транспорт чаралары һәм техниканың башка төрләре булуы турында (Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгына);

торак урынын билгеләнгән тәртиптә яшәү өчен яраксыз дип тану турында (җирле үзидарә органнарына);

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәрен түләү буенча бурычлар булуы (булмавы) турында (Федераль салым хезмәтенә) (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була);

индивидуаль шәхси счетның иминият номеры турында (Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан ) (әлеге абзац таләпләре 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәл була);

баланы (балаларны) гомуми белем бирү оешмасында укыту турында (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгына);

әҗәте булган затның иректән мәхрүм итү, арест астында тору, мәҗбүри дәвалануда булу рәвешендә җәза үтүгә бәйле рәвештә алимент түләттерелә алмый торган затның кереме булмавы турында (Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондына) (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була);

алимент түләүдән качу сәбәпле ата-аналарны эзләтү турында ( Федераль суд приставлары хезмәтеннән);

ата-аналарны җинаять кылган өчен җинаять җаваплылыгына тарту турында (Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенә);

вәкил вәкаләтләрен раслаучы документ турында (Федераль нотариаль палатага);

паспортның гамәлдә булуын тикшерү турында (Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгына);

фамилия-исем төркемнәренең, туу датасының, женеснең һәм СНИЛС туры килүе турында (Федераль салым хезмәтенә);

18 яшькә кадәрге инвалид баланы яисә балачактан I төркем инвалидны яисә хезмәткә сәләтсез затларны караган затлар турында (Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондына) (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була);

мөрәҗәгать итүченең яки аның гаилә әгъзаларының иректән мәхрүм итү

урыныннан чыгарылуы турында (Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенә);

мөрәҗәгать итүченең һәм гаилә әгъзаларының ИНН турында (Федераль салым хезмәтенә);

«һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын куллану кысаларында алынган керемнәр күләме турында (Федераль салым хезмәтенә);

Россия Федерациясе субъекты тарафыннан билгеләнгән чорда элегрәк алынган түләү турында (Социаль тәэминатның бердәм дәүләт мәгълүмат системасына);

ата-ананың икенчесенең түләүне алмавы турында (Социаль тәэминатның бердәм дәүләт мәгълүмат системасына);

фамилиясен, исемен, әтисенең исемен алыштыру турында (Федераль салым хезмәтенә).

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза һәм документларны кабул итү һәм теркәү көнендә гамәлгә ашырыла. Вәкаләтле орган ведомствоара гаризаларны карый һәм законнарда билгеләнгән срокларда җавап җибәрә.

Процедураның нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турында рәсми мөрәҗәгать.

Әлеге органнарга ведомствоара мәгълүмат сорау турында гарызнамә ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасын һәм аңа тоташтырыла торган ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең региональ системаларын кулланып, мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү максатында җибәрелә.

3.4.3. Әлеге Регламентның 2.6.2 пунктында каралган белешмәләр ведомствоара гарызнамәләр буенча әлеге документлар белән эш итүче органнар тарафыннан электрон формада, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү кагыйдәләрен, шул исәптән Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм (яисә) җирле үзидарә органнары арасында ведомствоара мәгълүмат хезмәттәшлекне оештыруның киңәш ителә торган кагыйдәләрен раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2021 елның 23 июнендәге 963 номерлы карары нигезендә ведомствоара гаризаны юллаган вакыттан башлап 48 сәгатьтән артып китмәгән чорда бирелә.

3.4.4. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кәгазь чыганакта башкарылырга мөмкин:

1) сорала торган белешмәләр электрон формада булмауга бәйле рәвештә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне электрон формада гамәлгә ашырып булмаган очракта;

2) ведомствоара рәсми мөрәҗәгать җибәргәндә, кәгазь чыганакта документларның оригиналларын тапшырырга кирәк булганда.

Әгәр ведомствоара хезмәттәшлек кәгазь чыганакта гамәлгә ашырылса, әлеге Регламентның 2.6.2 пунктында каралган белешмәләр әлеге белешмәләрне үз эченә алган документлар белән эш итүче органнар тарафыннан бирелә.

210-ФЗ номерлы федераль законның $7^2$ статьясының 3 өлеше нигезендә ведомствоара гаризаларга җавап әзерләү һәм җибәрү срогы ведомствоара гарызнамә алынган көннән башлап биш эш көненнән артырга тиеш түгел.

Процедураның нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турында җибәрелгән гарызнамәләр, сорала торган документларны (аларның күчермәләрен яки аларда булган белешмәләрне) алу.»;

Белешмәләрне куллануның максатлары булып мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документларның дөреслеген билгеләү, шулай ук законнарны һәм мөрәҗәгать итүченең хокукларын бозу очракларын булдырмый торган карарлар кабул итү тора;»;

3.5.4.1 пунктта:

беренче абзацта «салымнар һәм җыемнар» сүзләрен «салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәрен түләү» сүзләренә алмаштырырга (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була);

бишенче абзацта «салымнар һәм җыемнар» сүзләрен «салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәрен түләү» сүзләренә алмаштырырга (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була);

3.5.4.2 пунктның беренче абзацында «салымнар һәм җыемнар» сүзләрен «салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәрен түләү» сүзләренә алмаштырырга (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була);

4 бүлектәге 4.6 пунктны түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Белешмә телефоннар, дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр Министрлыкның рәсми сайтында (http://mtsz.tatarstan.ru) урнаштырыла.»;

6 нчы кушымтада «салымнар һәм җыемнар» сүзләрен «салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәрен түләү» сүзләренә алмаштырырга;

кушымта (белешмәлек) үз көчен югалткан дип танырга.

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Тәрбиягә алынганнарын да исәпкә алып, 18 яшькә кадәр өч һәм аннан күбрәк баласы булган гаиләләргә субсидияләр билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2014 елның 8 декабрендәге 675 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 06.06.2016 №315, 28.11.2016 №668, 08.06.2017 №349, 07.05.2018 №350, 18.09.2018 №858, 22.04.2019 №290, 28.08.2019 №655, 07.11.2019 №933, 28.02.2020 №135, 13.07.2020 №499, 09.10.2020 №717, 04.06.2021 №395, 07.09.2021 №640, 15.04.2022 №280 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Тәрбиягә алынганнарын да исәпкә алып, 18 яшькә кадәр өч һәм аннан күбрәк баласы булган гаиләләргә субсидияләр билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

2 бүлектә:

2.3.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе аны алу буенча сайланган ысул белән мөрәҗәгать итүчегә бирелә (җибәрелә):

язма рәвештә – шәхсән яки почта адресы буенча;

электрон документ формасында – электрон почта адресына һәм (яки) мөрәҗәгать итүченең Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы шәхси кабинетына.

Кабул ителгән карар турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр телефонга смс-хәбәр итеп, электрон почта аша җибәрелергә мөмкин.»;

түбәндәге редакциядә 2.3.3 пунктын өстәргә:

«2.3.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып реестр язуы тормый.»;

түбәндәге редакциядә 2.3.4 пунктын өстәргә:

«2.3.4. Субсидия билгеләү турында карар реквизитлары:

карар номеры һәм датасы;

карар кабул итүгә вәкаләтле органның исеме;

гаризаның номеры һәм датасы;

мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);

карар кабул итүгә вәкаләтле затның (алга таба – вәкаләтле зат) вазыйфасы;

Вәкаләтле затның фамилиясе, исеме, ата исеме (соңгысы – булган очракта);

электрон имза турында белешмәләр.

Субсидия бирүдән баш тарту турында карар реквизитлары:

субсидия бирүдән баш тарту турында карар номеры һәм датасы;

карар кабул итүгә вәкаләтле органның исеме;

Мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);

мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документлар;

субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул итү нигезләре;

вәкаләтле затның вазыйфасы;

Вәкаләтле затның фамилиясе, исеме, ата исеме (соңгысы – булган очракта);

электрон имза турында белешмәләр.»;

2.4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4.1. Гариза һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан шәхсән тапшырылган очракта, дәүләт хезмәте Үзәк бүлекчәсе тарафыннан гариза һәм әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән документлар теркәлгән көннән алып 10 календарь көн эчендә күрсәтелә.

Гариза һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар почта аша юллап җибәрелгән очракта, дәүләт хезмәте Үзәк бүлекчәсе тарафыннан гариза һәм әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән документлар теркәлгән көннән алып 10 календарь көн эчендә күрсәтелә.

Гариза һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы шәхси кабинет аша бирелгән очракта, дәүләт хезмәте Үзәк бүлекчәсе тарафыннан гаризага эшләр номенклатурасы нигезендә номер һәм Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы шәхси кабинетта чагылдырыла торган «Документлар тикшерү» статусы бирелгән көннән башлап 10 эш көне эчендә күрсәтелә.»;

2.4.3 пунктта «салымнар һәм җыемнар» сүзләрен «салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәрен түләү» сүзләренә алмаштырырга (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була);

2.6.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.6.2. Вәкаләтле органнардан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алына торган документлар (белешмәләр):

яшәү урыны һәм тору урыны буенча теркәлү исәбе турында (Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгыннан);

баланы гаиләгә тәрбиягә тапшыру турында (җирле үзидарә органнарыннан);

баланың тууын дәүләт теркәве турында (Федераль салым хезмәтеннән);

баланы чыгару датасын күрсәтеп, гомуми белем бирү оешмасында, һөнәри белем бирү оешмасында укыту турында (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгыннан);

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү буенча бурычлар булуы (булмавы) турында белешмәләр (Федераль салым хезмәтеннән);

индивидуаль шәхси счетның иминият номеры (Пенсия һәм социаль иминият фондыннан).

Мөрәҗәгать итүченең Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша мөрәҗәгатендә мөрәҗәгать итүче паспортының чын булуын раслау турындагы белешмәләр ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча өстәмә рәвештә алына.

Мөрәҗәгать итүче югарыда аталган белешмәләрне раслый торган документларны үз инициативасы белән дә тапшырырга хокуклы.

Әлеге документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмалардан алынырга мөмкин, шул исәптән, мондый мөмкинлек булганда, электрон формада да, һәм әлеге Регламентның 2.6 пунктының 2.6.1 пунктчасында күрсәтелгән документларны тапшыру өчен әлеге Регламентта каралган тәртиптә тапшырылырга мөмкин.»;

2.8.1 пунктта «салымнар һәм җыемнар» сүзләрен «салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәрен түләү» сүзләренә алмаштырырга (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була);

2.8.2 пунктның дүртенче абзацында «салымнар һәм җыемнар» сүзләрен «салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәрен түләү» сүзләренә алмаштырырга (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була);

2.12.4 пунктның «в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) Үзәк бүлекчәсе хезмәткәрләре тарафыннан инвалидларга башка затлар белән бертигез рәвештә дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен комачау иткән каршылыкларны бетерүдә кирәкле башка ярдәмне күрсәтү;»;

2.14.4 пунктын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Алдан язылу булмау мөрәҗәгать итүчене чират тәртибендә кабул итүгә комачауламый.»;

3 бүлектә:

3.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3. Гаризаны һәм документларны кабул итү һәм теркәү.

3.3.1. Мөрәҗәгать итүче субсидия билгеләү турында гаризаны Үзәк бүлекчәсенә, әлеге Регламентның 2.6 пунктының 2.6.1 пунктчасына туры китереп, документларны теркәп тапшыра.

Гариза һәм документларның Россия Федерациясе законнары нигезендә

таныкланган күчермәләре почта аша җибәрелергә мөмкин.

Электрон рәвештә җибәрелә торган гариза һәм документлар (документларның күчермәләре) 63-ФЗ номерлы федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә имзалана (таныклана) һәм Идарәгә (бүлеккә) электрон чыганаклардан һәм (яисә), Интернет челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып тапшырыла.

Үзәк бүлекчәсенә почта, электрон почта, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша җибәрелгән гариза һәм документлар мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә гаризаны һәм документларны карау өчен билгеләнгән тәртиптә карап тикшерелә.

Мөрәҗәгать итүче, гаризаны Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша электрон формада тапшыру өчен, түбәндәге гамәлләрне башкара:

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында авторизация уза;

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында электрон гариза формасын ача;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган белешмәләрне үз эченә алган электрон гариза формасын тутыра;

электрон формадагы документларны яки электрон документ үрнәкләрен электрон гариза формасына беркетә (кирәк булганда);

электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм килешү фактын раслый (электрон гариза формасында ризалык турында тиешле тамга билгели);

хәбәр ителгән белешмәләрнең дөреслеген раслый (электрон гариза рәвешендә тиешле тамга билгели);

тутырылган электрон гаризаны җибәрә (электрон гариза рәвешендәге тиешле төймәгә баса);

электрон гариза әлеге Регламентның 2.6 пунктының 2.6.1 пунктчасы таләпләре нигезендә имзалана;

электрон гаризаның җибәрелүе турында белдерү ала.

Гаризаны формалаштыру, гаризаны өстәмә рәвештә нинди дә булса башка формада тапшыру зарурлыгыннан тыш, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Гаризаны формалаштырганда мөрәҗәгать итүче өчен түбәндәгеләр тәэмин ителә:

а) гаризаның һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларның күчермәләрен ясау һәм аларну саклау мөмкинлеге;P128

б) гаризаның электрон формасы күчермәсен кәгазьдә бастырып чыгару;

в) файдаланучы ихтыярына карап, шул исәптән гаризаның электрон формасына ялгыш керткәндә һәм күрсәткечләрне яңадан кертү зарурлыгы булганда да, теләсә кайсы вакытта электрон гариза формасына элегрәк кертелгән күрсәткечләрне саклау;

г) БИАС булмаган мәгълүматларга кагыла торган өлешендә, БИАС

системасында урнаштырылган һәм Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында басылып чыккан мәгълүматларны файдаланып, мөрәҗәгать итүче тарафыннан белешмәләр кертә башлаганчыга кадәр электрон гариза формасы кырларын тутыру;

д) элегрәк кертелгән мәгълүматларны югалтмыйча, электрон гариза формасын тутыруның теләсә кайсы этапларына яңадан әйләнеп кайту;

е) мөрәҗәгать итүченең Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында бер елдан азрак булмаган чорда үзе элегрәк тапшырган гаризаларны, шулай ук кимендә 3 ай эчендә өлешчә формалаштырган гаризаларны карау мөмкинлеге.

Формалаштырылган һәм имзаланган гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар Үзәк бүлекчәсенә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша җибәрелә.

Үзәк бүлекчәсенә почта, электрон почта, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша җибәрелгән гариза һәм документлар мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә гаризаны һәм документларны карау өчен билгеләнгән тәртиптә карап тикшерелә.

3.3.2. Үзәк бүлекчәсе хезмәткәре дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле булган, әлеге Регламентның 2.7 пунктында каралган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булу-булмавын тикшерә.

Документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре булмаса, Үзәк бүлекчәсе белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

гаризаны кабул итә һәм мөрәҗәгатьләрне теркәү журналында (3 нче кушымта) терки;

гаризаны һәм документларны кабул итү датасы, кергәндә беркетелгән номеры (мөрәҗәгать итүче шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта) турында тамгалап, мөрәҗәгать итүчегә язу тапшыра, гариза почта буенча һәм (яки), «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып җибәрелгән очракта, гаризаны теркәү датасы һәм алынганда беркетелгән номеры турында белдерү җибәрә яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына гаризаны теркәү турында белдерү җибәрә (гариза Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы яки Татарстан Республикасы электрон инфоматлары аша җибәрелгән очракта).

Документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре булган очракта (мөрәҗәгать итүче шәхсән мөрәҗәгать иткәндә), Үзәк бүлекчәсе белгече мөрәҗәгать итүчегә документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре турында телдән хәбәр итә һәм, документларны кабул итүдән баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген аңлатып, барлык документларны аңа кайтарып бирә. Гаризаны һәм документларны почта аша һәм (яисә), «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән алганда, Үзәк бүлекчәсе белгече гаризаны һәм документларны, документларны кабул итүдән һәм гаризаны теркәүдән баш тарту сәбәпләрен язмача аңлатып, кайтарып бирә.

Гаризаны Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте инфоматлары аша биргән

очракта, гаризаны теркәүдән баш тарту турында белдерү мөрәҗәгать итүченең Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы шәхси кабинетына җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар түбәндәгечә башкарыла:

шәхсән кабул иткәндә яисә гариза һәм документлар почта аша килгәндә – гариза һәм документлар алынган көнне;

гариза һәм документлар Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте инфоматлары аша килгәндә яки почта аша, шул исәптән «Интернет» челтәре аша», электрон почта буенча электрон документлар рәвешендә килгәндә, – гариза һәм документлар Үзәк бүлекчәсенә килгән көнне яисә, гариза һәм документлар Үзәк бүлекчәсенең эш вакыты тәмамлангач килгән очракта, киләсе эш көнендә. Гариза Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте инфоматлары аша килгәндә яки почта аша, шул исәптән «Интернет» челтәре аша», электрон почта буенча электрон документлар рәвешендә ял яки эшләми торган бәйрәм көннәрендә килгән очракта, – Үзәк бүлекчәсенең ял яки эшләми торган бәйрәм көненнән соң килүче беренче эш көнендә.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән документлар, гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында теркәү язуы, язу яисә мөрәҗәгать итүчегә кайтарып бирелгән документлар, мөрәҗәгать итүчегә документларны кабул итүдән баш тарту турында телдән (язмача) белдерү.»;

3.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4. Ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга (оешмаларга) җибәрү

3.4.1. Үзәк бүлекчәсендә теркәлгән гариза гарызнамә җибәрү өчен нигез булып тора.

3.4.2. Үзәк бүлекчәсе белгече электрон рәвештә түбәндәге белешмәләрне ала:

яшәү урыны һәм тору урыны буенча теркәлү исәбе турында (Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгыннан);

баланың тууын дәүләт теркәве турында (Федераль салым хезмәтеннән);

баланы чыгару датасын күрсәтеп, гомуми белем бирү оешмасында, һөнәри белем бирү оешмасында укыту турында (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгыннан);

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза алынган көнне башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: вәкаләтле органнардан алынган белешмәләр.

3.4.2. Субсидия билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар кабул итү өчен кирәкле белешмәләр Үзәк бүлекчәсендә булмаса, Үзәк бүлекчәсе белгече электрон рәвештә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасы ярдәмендә түбәндәге белешмәләрне бирү турында гарызнамәләр җибәрә:

яшәү урыны һәм тору урыны буенча теркәлү исәбе турында (Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгына);

баланы гаиләгә тәрбиягә тапшыру турында (җирле үзидарә органнарына);

балаларның тууын дәүләт теркәвенә алу турында (Федераль салым хезмәтенә);

баланы чыгару датасын күрсәтеп, гомуми белем бирү оешмасында, һөнәри белем бирү оешмасында укыту турында (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгына);

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәрен түләү буенча бурычлар булуы (булмавы) турында (Федераль салым хезмәтенә) (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була);

мөрәҗәгать итүче паспортының гамәлдә булуын раслау турында – Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша мөрәҗәгать иткән очракта (Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгына);

индивидуаль шәхси счетның иминият номеры турында (Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондына) (әлеге абзац таләпләре 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәл була);

Әлеге органнарга ведомствоара мәгълүмат сорау турында гарызнамә ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасын һәм аңа тоташтырыла торган ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең региональ системаларын кулланып, мөрәҗәгать итүчегә  дәүләт хезмәте күрсәтү максатында җибәрелә.

3.4.3. Әлеге Регламентның 2.6.2 пунктында каралган белешмәләр ведомствоара гарызнамәләр буенча әлеге документлар белән эш итүче органнар тарафыннан электрон формада, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү кагыйдәләрен, шул исәптән Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм (яисә) җирле үзидарә органнары арасында ведомствоара мәгълүмат хезмәттәшлекне оештыруның киңәш ителә торган кагыйдәләрен раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2021 елның 23 июнендәге 963 номерлы карары нигезендә  ведомствоара гаризаны юллаган вакыттан башлап 48 сәгатьтән артып китмәгән чорда бирелә.

3.4.4. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кәгазь чыганакта башкарылырга мөмкин:

1) сорала торган белешмәләр электрон формада булмауга бәйле рәвештә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне электрон формада гамәлгә ашырып булмаган очракта;

2) ведомствоара рәсми мөрәҗәгать җибәргәндә, кәгазь чыганакта документларның оригиналларын тапшырырга кирәк булганда.

Әгәр ведомствоара хезмәттәшлек кәгазь чыганакта гамәлгә ашырылса, әлеге Регламентның 2.6.2 пунктында каралган белешмәләр әлеге белешмәләрне үз эченә алган документлар белән эш итүче органнар тарафыннан бирелә.

210-ФЗ номерлы федераль законның $7^2$ статьясының 3 өлеше нигезендә ведомствоара гаризаларга җавап әзерләү һәм җибәрү срогы ведомствоара гарызнамә алынган көннән башлап биш эш көненнән артырга тиеш түгел.

Процедураның нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турында җибәрелгән гарызнамәләр, сорала торган документларны (аларның күчермәләрен яки аларда булган белешмәләрне) алу.»;

Белешмәләрне куллануның максатлары булып мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документларның дөреслеген билгеләү, шулай ук законнарны һәм

мөрәҗәгать итүченең хокукларын бозу очракларын булдырмый торган карарлар кабул итү тора;»;

3.5.4.1 пунктта:

беренче абзацта «салымнар һәм җыемнар» сүзләрен «салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү» сүзләренә алмаштырырга (әлеге абзац таләпләре 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була);

бишенче абзацта «салымнар һәм җыемнар» сүзләрен «салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәрен түләү» сүзләренә алмаштырырга (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була);

3.5.4.2 пунктның беренче абзацында «салымнар һәм җыемнар» сүзләрен «салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәрен түләү» сүзләренә алмаштырырга (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була);

4.6 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Белешмә телефоннар, дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр Министрлыкның рәсми сайтында (http://mtsz.tatarstan.ru) урнаштырыла.»;

8 нче кушымтада «салымнар һәм җыемнар» сүзләрен «салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәрен түләү» сүзләренә алмаштырырга (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була);

9 нчы кушымтада «салымнар һәм җыемнар» сүзләрен «салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәрен түләү» сүзләренә алмаштырырга (әлеге абзац таләбе 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була);

кушымта (белешмәлек) үз көчен югалткан дип танырга.